**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Якты Күл авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«11» апрель 2024 ел                                                                                    № 9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 11 апрелендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 27.11.2023 ел, № 11, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены карары 27.11.2023 ел, № 12 түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертүгә килешәсезме:

2024 елда Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым тәртибендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Якты Күл авылы территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алумәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 225 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 135 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 131 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 27.11.2023 ел, № 11, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены карары 27.11.2023 ел, № 12 түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2024 елда Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым тәртибендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Якты Күл авылы территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев